**МИНИСТЕРСТВО ЮСТИЦИИ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮСТИЦИЯ МИНИСТРЛЫГЫ**

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

**11.12.2019** г. Казань **№ 162од**

Татарстан Республикасының
берничә муниципаль районында,
шәһәр округларында халык
белән чараларны уздыруны
килештерү буенча дәүләт
хезмәте күрсәтүнең
административ регламентына
үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләрен күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү хакында» 2010 елның 2 ноябрендәге 880 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында» 2019 елның 16 сентябрендәге 834 номерлы карары чыгуга һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Дәүләт хакимиятенең башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләрен күрсәтүнең административ регламентлары системасын эшләү турында» 2006 елның 16 июнендәге 310 номерлы карары һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының "Мәдәни мирас объектлары (тарихи һәм мәдәни ядкәрләр), ачыкланган мәдәни мирас объектлары территорияләрендә халык белән чара үткәрү тәртибен раслау турында" Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 4 декабрендәге 953 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында 2019 елның 18 сентябрендәге 844 номерлы карары үз көчләрен югалткан дип танылуга бәйле рәвештә, боерам:

1. Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгының 2017 елның 18 октябрендәге 01-02/125 номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасының берничә муниципаль районы, шәһәр округлары территорияләрендә халык белән чараларны уздыруны килештерү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына (2018 елның 5 июнендәге 50 од,

2018 елның 21 сентябрендәге 105 од, 2019 елның 13 сентябрендәге 120 од номерлы боерыклар белән кертелгән үзгәрешләр белән), аны түбәндәге редакциядә бәян итеп (кушымта итеп бирелә), үзгәреш кертергә.

2. Әлеге боерык рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керә дип билгеләргә.

Министр Р.И. Зәһидуллин

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгының 2017 елның 18 октябрендәге 01-02/125 боерыгы белән расланган (Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгының 11.12.2019 елның 162од номерлы боерыгы редакциясендә)

## Татарстан Республикасының берничә муниципаль районы, шәһәр округлары территорияләрендә халык белән чараларны уздыруны килештерү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентны

### 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1.Татарстан Республикасының берничә муниципаль районы, шәһәр округлары территорияләрендә халык белән чараларны уздыруны килештерү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүгә административ регламентны (алга таба – Регламент) Татарстан Республикасының берничә муниципаль районы, шәһәр округлары территорияләрендә халык алдындагы чараларны уздыруны килештерү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең (алга таба – дәүләт хезмәте) стандартын һәм тәртибен билгели.

1.2. Гариза бирүчеләр - юридик яки физик затлар.

1.3. Дәүләт хезмәте Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы (алга таба - Министрлык) тарафыннан күрсәтелә.

1.3.1. Министрлык урнашкан урын: Казан шәһ., Кремль ур., 16 йорт.

Министрлыкның эш графигы: шимбә һәм якшәмбе көннәреннән кала көн саен, дүшәмбе - пәнҗешәмбе 9.00 дән 18.00 гә кадәр, җомга 9.00 дән 16.45 кә кадәр, төшке аш вакыты 13.00 дән 13.45 кә кадәр.

Гаризаларны кабул итү графигы: шимбә һәм якшәмбе көннәреннән кала көн саен, Министрлыкның эш сәгатьләрендә.

Җәмәгать транспорты белән “Университет” тукталышына кадәр килергә:

10, 10а, 30, 35, 35а, 54, 63, 91нче автобуслар;

2, 3, 5, 7, 8 нче троллейбуслар.

Бинага керү пропуск һәм (яки) шәхесне ачыклаучы документ буенча.

1.3.2. Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгының җирле үзидарә органнарына консультация-методик ярдәм бүлеге (алга таба – Бүлек) телефоннары: (843) 292-11-67; (843) 223-06-47.

1.3.3. “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Министрлыкның рәсми сайты адресы (алга таба – "Интернет" челтәре):http://minjust.tatarstan.ru, электрон почта адресы:minjust@tatar.ru.

1.3.4. Дәүләт хезмәте турындагы мәгълүмат алынырга мөмкин:

1.3.1. гариза бирүчеләр белән эшләү өчен дәүләт хезмәте күрсәтү турында текст рәвешендәге мәгълүматны эченә алган һәм Министрлык биналарында урнаштырылган дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы мәгълүмат стендларыннан;

1.3.2. “Интернет” челтәре аша:

Министрлыкның рәсми сайтында (http://www.minjust.tatarstan.ru);

Татарстан Республикасының дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр порталында (http://uslugi.tatarstan.ru);

3)Министрлыкка телдән мөрәҗәгать иткәндә (шәхсән яки телефон аша);

4) Министрлыкка язма рәвештә (шул исәптән электрон документ форматында да) мөрәҗәгать иткәндә.

1.3.5. Министрлыкның урнашкан урыны, белешмә телефоннары, эш графигы, рәсми сайты адресы, шулай ук электрон почтасы турындагы мәгълүматлар Бүлек белгече тарафыннан Министрлыкның рәсми сайтына, “Татарстан Республикасы дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр реестры” дәүләт мәгълүмат системасына һәм Татарстан Республикасы дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр порталына урнаштырыла.

Министрлыкның гариза бирүчеләр белән эшләү өчен каралган бүлмәләрендәге мәгълүмат стендларында урнаштырылган мәгълүмат дәүләт хезмәте күрсәтү турында әлеге Регламентның 1.3.1, 2.1, 2.3 - 2.5, 2.7, 2.9, 2.11, 5.1 пунктларында (пунктчасында) күрсәтелгән ике дәүләт телендәге мәгълүматларны үз эченә ала.

1.4. Дәүләт хезмәтен күрсәтү түбәндәгеләр нигезендә гамәлгә ашырыла:

“Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында” 1995 елның 24 ноябрендәге 181-ФЗ номерлы Федераль закон (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 1995, № 48, 4563 бит, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) (алга таба – 181-ФЗ номерлы федераль закон);

2004 елның 19 июнендәге “Җыелышлар, митинглар, демонстрацияләр, урам йөрешләре һәм пикетлар турында” 54-ФЗ номерлы федераль закон (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2004, № 25, 2485бит, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) (алга таба –54-ФЗ номерлы федераль закон);

2010 елның 27 июлендәге “Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында” 210-ФЗ номерлы федераль закон (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2010 елның 2 августыннан, № 31, 4179 бит, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) (алга таба - № 210-ФЗ номерлы федераль закон);

2011 елның 6 апрелендәге “Электрон имза турында” 63-ФЗ номерлы федераль закон (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 11.04.2011, № 15, 2036 бит, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) (алга таба –63-ФЗ номерлы федераль закон);

Россия Федерациясе Президентының 2012 елның 7 маендагы “Дәүләт идарәсе системасын камилләштерүнең төп юнәлешләре турында” № 601 номерлы Указы (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 07.05.2012, № 19, 2338 бит (алга таба - № 601 номерлы Указ);

“Гражданнарның Татарстан Республикасында җыелышлар, митинглар, демонстрацияләр, урам йөрешләре һәм пикетлар уздыруга хокукларын гамәлгә ашыруга шартлар тудыру турында” 2012 елның 25 декабрендәге 91-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы (Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Җыелма

басмасы, 2012, № 12, 1883 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) (алга таба –91-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2006 елның 22 февралендәге “Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы сораулары” № 68 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Юстиция Министрлыгы турындагы нигезләмәсе (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм башкарма хакимиятнең республика органнарының норматив актлары җыелмасы, 2006, № 10, 0272 бит, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) (алга таба – Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 68 номерлы карары белән расланан Нигезләмә) тарафыннан расланган;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 2 ноябрендәге “Татарстан Республикасының дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтелүнең административ регламентын эшләү һәм раслау тәртибен раслау һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында” № 880 номерлы карары (алга таба – Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 880 номерлы карары) (“Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм башкарма хакимиятнең республика органнарының норматив актлары җыентыгы”, 2010, № 46, 2144 бит, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып).

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының “Татарстан Республикасында җыелышлар, митинглар, демонстрацияләр, урам йөрешләре һәм пикетлар уздыру буенча вәкаләтле органы турында” 2013 елның 24 июнендәге 436 номерлы карары (“Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм башкарма хакимиятнең республика органнарының норматив актлары җыентыгы”, 09.07.2013, № 51,1658 бит, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) (алга таба – Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 436 номерлы карары);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының “Мәдәни мирас объектлары (тарихи һәм мәдәни ядкәрләр), ачыкланган мәдәни мирас объектлары территорияләрендә халык белән чара үткәрү тәртибен раслау турында” 2013 елның 4 декабрендәге 953 номерлы карары (“Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм башкарма хакимиятнең республика органнарының норматив актлары җыентыгы”, 13.12.2013, № 92, 3039 бит, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) (алга таба – Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 953 номерлы карары).

1.5. Әлеге Регламентта түбәндәге терминнар һәм билгеләмәләр кулланыла:

халык белән чара - ачык, тыныч, һәркем катнаша ала торган, җыелыш, митинг, демонстрация, урам йөреше яки пикет рәвешендә, яки бу формаларның төрле кушылмалары рәвешендә уздырыла торган, Россия Федерациясе гражданнары, сәяси партияләр, башка иҗтимагый берләшмәләр һәм дини берләшмәләр тарафыннан, шул исәптән транспорт чараларын да кулланып уздырыла торган чара.

Гавами чараның максаты булып фикерләрне ачык формалаштыру һәм тәкъдим итү, илнең сәяси, икътисадый, социаль һәм мәдәни тормышындагы төрле мәсьәләләр һәм тышкы сәясәт буенча таләпләрне алга чыгару яки дәүләт хакимиятенең закон чыгару (вәкиллекле) органы депутатының, муниципаль

берәмлекнең вәкиллекле органы депутатының саулаучыларны үз эшчәнлеге белән таныштыруы тора;

гариза бирүче – дәүләт хезмәтен күрсәтүне сорап телдән, язма рәвештә яки электрон формадагы гариза белән мөрәҗәгать итүче физик яки юридик зат (аларның вәкаләтле вәкилләре);

халык белән чараны уздыру турында гариза –54-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә аны уздыру барышында иминлекне һәм хокук тәртибен саклау максатыннан халык белән чара уздырылу турында Министрлыкка хәбәр ителә торган документ;

халык белән чараны уздыру регламенты – халык белән чараны уздыруның һәр этабы өчен җаваплы кешеләр күрсәтелеп, төп этапларының сәгатьле тасвирламасын (сәгатьле планын) үз эченә алган документ, ә халык белән чара транспорт чараларын да кулланып уздырыла торган очракта транспорт чараларын куллану турындагымәгълүматны да үз эченә ала;

техник хата - Министрлык тарафыннан җибәрелгән һәм чараны уздыруны килештерү турындагы карарда күрсәтелгән мәгълүматларның, мөрәҗәгатьтә күрсәтелгән мәгълүматларның дөреслеккә туры килмәвенә китерә торган хата (хәреф хаталары, грамматик яки арифметик хата);

дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтелә торган күпфункцияле үзәкнең ерактагы эш урыны - дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтелә торган күпфункцияле үзәкнең Татарстан Республикасы муниципаль районы (шәһәр округы) шәһәр яки авыл җирлегендә Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәкләре эшчәнлеген оештыруның Россия Федерациясе Хөкүмәтенең “Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәкләре эшчәнлеген оештыру кагыйдәләрен раслау турында” 2012 елның 22 декабрендәге 1376 номерлы карары белән расланган кагыйдәләрнең 34 пункты нигезендә булдырыган территориаль аерымланган структур бүлекчәсе (офис);

мәдәни мирас объектлары – күчемсез милек объектлары (археологик мирас объектларын да кертеп) һәм аларга тарихи территорияләр, рәссамчылык, скульптурачылык, декоратив-гамәли сәнгать, фән һәм техника объектлары һәм тарихи вакыйгалар нәтиҗәсендә килеп чыккан башка матди сәнгать предметлары белән бәйле булган, тарих, археология, архитектура, шәһәр төзелеше,сәнгать, фән һәм техника, эстетика, этнология яки антропология, социаль мәдәният күзлегеннән караганда кыйммәткә ия булган һәм гасырлар һәм цивилизацияләр шаһитләре, мәдәниятнең килеп чыгышы һәм үсеше турында турыдан-туры мәгълүмат чыганагы булып торучы башка объектлар.

Башка төшенчәләр һәм терминнар 54-ФЗ номерлы һәм 210-ФЗ номерлы Федераль законнар нигезендә кулланыла.

## 2. Дәүләт хезмәте күрсәтү стандарты

| Дәүләт хезмәте күрсәтү стандартына таләпнең аталышы | Стандартка булган таләпләр эчтәлеге | Хезмәт күрсәтү яки таләпне билгеләүче норматив акт |
|---|---|---|
| 2.1. Дәүләт хезмәтенең аталышы | Татарстан Республикасының берничә муниципаль районы, шәһәр округларында халык белән чаралар уздыруны килештерү | 54-ФЗ номерлы Федераль законның 7, 12 статьялары |
| 2.2. Башкарма хакимият органының исеме | Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы | 91-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законының 3 статьясының 3 өлеше;<br>Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 436 номерлы карары;<br>Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 68 номерлы карары белән расланган Нигезләмәнең 4.1.27 пункты; |
| 2.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсенең тасвирламасы | Халык белән чараны уздыруны килештерү турындагы яки халык белән чараны уздыруны килештерүдән баш тарту турындагы Татарстан Республикасы юстиция министры карары белән рәсмиләштерелгән карар | 54-ФЗ номерлы Федераль законның 7 статьясы; |
| 2.4. Дәүләт хезмәтен күрсәтүдә катнаша торган оешмаларга мөрәҗәгать итү кирәклеген дә исәпкә алып, дәүләт хезмәтен күрсәтү вакыты, Россия Федерациясе законнарында туктатып тору мөмкинлеге каралган очракта, дәүләт | Халык белән чара уздыру турында гариза теркәлгән көннән өч эш көне дәвамында.<br>Халык белән чара мәдәни мирас объектлары территорияләрендә уздырылган очракта, - дүрт эш көне дәвамында. | |
| | | 91-ЗРТ номерлы Татарстан |

| | | |
|---|---|---|
| хезмәтен күрсәтүне туктатып тору вакыты, дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәсе булып торучы документларны тапшыру (юллау) срогы | Гариза бирүче тарафыннан 54-ФЗ номерлы Федераль закон таләпләрен һәм белдерү бирүнең 91-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы белән билгеләнгән тәртибен бозуны бетергәннән соң халык белән чара оештырылуга өч календарь көн кала бирелгән белдерү мондый белдерү теркәлгән көннән ике календарь көн дәвамында карала. Әгәр дә чарага кадәр өч көннән кимрәк вакыт калган булса, халык белән чараны оештыручы башка дата тәкъдим итәргә тиеш, аннан соң гариза халык белән чараны уздыру датасы үзгәрү турындагы хат теркәлгән көннән алып биш эш көне эчендә карала.<br>Дәүләт хезмәтен күрсәтү вакытын туктатып тору Россия Федерациясе законнары белән каралмаган.<br>Дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәсе булып торучы документны тапшыру гариза бирүче мөрәҗәгать иткән көнне башкарыла.<br>Дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәсе булып торучы документны гаризада күрсәтелгән элемтә чарасын кулланып (почта аша, электрон адреска) тапшыру дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәсе рәсмиләштерелгән һәм теркәлгән көнне гамәлгә ашырыла. | Республикасы Законының 3 статьясы; |
| 2.5. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен, шулай ук дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарур һәм мәҗбүри булып торучы хезмәтләр күрсәтү өчен законнар яки башка норматив хокукый актлар нигезендә кирәкле булган, гариза бирүче тарафыннан бирелергә тиешле документларның тулы исемлеге, гариза бирүченең аларны алу ысуллары, шул исәптән электрон формада да, аларны бирү тәртибе | Халык белән чара уздыру турында белдерү (1 нче кушымта) үз эченә түбәндәге мәгълүматларны ала:<br>1) халык белән чараның фикер алышуга чыгарылган мәсьәләнең һәм (яки) мондый чараны уздыруга сәбәп булып торучы вакыйганың төгәл формулировкасы белән булган максаты;<br>2) халык белән чара формасы – аны уздыру өчен 54- ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә белдерү таләп ителә торган митинг, демонстрация, урам йөреше яки пикет яки бу формаларның төрле катнашмалары формасындагы акция;<br>3) халык белән чара уздыру урыны (урыннары), катнашучыларның хәрәкәт маршрутлары, ә халык белән чара транспорт чараларын кулланып башкарылган очракта, транспорт чараларын файдалану турындагы мәгълүмат. Транспорт чараларын файдалану турындагы мәгълүмат дигәндә файдалану | 54-ФЗ номерлы Федераль законның 7 статьясы;<br>91-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законының 3 статьясы. |

| | | |
|---|---|---|
| | планлаштырыла торган транспорт чараларының гомуми саны, маршрутның озынлыгын, башлану һәм тәмамлану нокталарын, транспорт чарасының уртача хәрәкәт тизлеген дә кертеп, аларның хәрәкәт маршрутлары аңлашыла;<br>4) халык белән чара уздырылу көне, башлану һәм тәмамлану вакыты;<br>5) халык белән чарада катнашуга тәкъдим ителгән катнашучылар саны;<br>6) халык белән чараны оештыручының җәмәгать тәртибен саклауны оештыруы формасы һәм алымнары, халык белән чараны уздыру шартлары һәм анда катнашачак халык санынннан чыгып медицина ярдәмен оештыруы, халык белән чараны уздырганда тавыш көчәйткеч техник чаралар куллану нияте; | |
| | 7) халык белән чараны оештыручының фамилиясе, исеме, әтисенең исеме яки тулы аталышы, аның тору яки яшәү урыны яки урнашкан урыны турында мәгълүмат, кәрәзле телефон номеры һәм электрон почта адресы. Халык белән чараны оештыручы булып сәяси партияләр, башка иҗтимагый берләшмәләр һәм дини берләшмәләр, аларның төбәк бүлекләре һәм башка структур бүлекчәләре торган очракта белдерүдә халык белән чараны оештыруга җитәкчелек итүчегә яки аның законнар нигезендә билгеләнгән вәкаләтле затына мөнәсәбәттә әлеге пункт белән билгеләнгән мәгълүматлар бирелә;<br>8) халык белән чараны оештыручы тарафыннан чараны оештыру һәм уздыру буенча эшләрне башкаруга вәкаләт бирелгән затларның, тавыш көчәйткеч техник чаралар өчен җаваплы затларның, медицина ярдәме күрсәтүче затларның фамилияләре, исемнәре һәм әтиләренең исемнәре, аларның кәрәзле телефон номерлары, элекрон почталары адреслары;<br>9) халык белән чара уздыру турында белдерү бирү көне.<br>Халык белән чараны 54-ФЗ номерлы Федераль законның 3 статьясында билгеләнгән принциплар нигезендә уздыру турындагы белдерү халык белән чараны оештыручы һәм халык белән чараны оештыручы тарафыннан чараны оештыру һәм уздыру буенча эшләрне башкаруга вәкаләт бирелгән затлар тарафыннан имзалана. | |

| | | |
|---|---|---|
| | Белдерү халык белән чараны уздыручы тарафыннан шәхсән яки аның вәкиле тарафыннан язма формада бирелә.<br>Белдерүне биргәндә түбәндәге документлар да кушып бирелә:<br>1) Россия Федерациясе гражданины паспорты яки шәхесне ачыклаучы башка документ (оештыручы физик зат булса) яки юридик затның теркәлүе турында дәүләт теркәве таныклыгы (оештыручы юридик зат булса);<br>2) халык белән чараны оештыручы исеменнән чыгыш ясаучы затның вәкаләтләрен раслаучы документлар (вәкилләр өчен).<br>Белдерү бланкын халык белән чараны оештыручы Министрлыкка шәхсән мөрәҗәгать иткәндә алырга мөмкин. Бланкның электрон формасы Министрлыкның рәсми сайтында урнаштырылган.<br>Белдерү һәм аңа кушып бирелә торган документлар халык белән чараны оештыручы тарафыннан түбәндәге алымнарның берсе белән кәгазь вариантта тәкъдим ителергә (юлланырга) мөмкин:<br>шәхсән (ышаныч кәгазе нигезендә гариза бирүче исеменнән эш итүче зат тарафыннан);<br>почта аша.<br>Белдерү һәм документлар (документларның күчермәләре) Министрлыкка 63-ФЗ номерлы һәм 210-ФЗ номерлы Федераль законнар таләпләре нигезендә квалификацияле электрон имза куелган электрон документлар рәвешендә дә юллана ала. | |
| 2.6. Норматив хокукый актлар нигезендә дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле булган, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм башка оешмалар вәкаләтендә булучы һәм гариза бирүче аларны тәкъдим итү хокукына ия булган докуменларның тулы исемлеге, шулай ук гариза бирүченең аларны алу ысуллары, шул исәптән электрон формада да, | Әлеге категориягә караган документларны тапшыру таләп ителми. | |

| | | |
|---|---|---|
| аларны тәкъдим итү тәртибе; әлеге документлар аларның вәкаләтләрендә булган дәүләт органы, җирле үзидарә органы яки оешма | | |
| 2.7. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны алудан баш тарту өчен нигезләмәләрнең тулы исемлеге | Документларны кабул итеп алудан баш тарту өчен җирлек булып тора:<br>1) гариза 54-ФЗ номерлы Федераль законның 7 статьясы таләпләренә җавап бирмәгәндә;<br>2) халык белән чараны оештыручы яки аның вәкиле әлеге Регламентның 2.5 пунктында санап кителгән документларны тапшырмаганда | 54-ФЗ номерлы Федераль законның 7 статьясы |
| 2.8. Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору яки аны күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләмәләрнең тулы исемлеге | Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору өчен җирлек булып тора:<br>1) халык белән чараны уздыру турындагы гариза 54-ФЗ номерлы Федераль законның 5 статьясының 2 өлеше нигезендә халык белән чараны оештыручы була алмый торган зат тарафыннан бирелсә;<br>2) гаризада халык белән чара уздыру урыны сыйфатында 54-ФЗ номерлы Федераль закон һәм 91-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә анда халык белән чара уздыру тыела торган урын күрсәтелсә.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору өчен нигезләр юк. | 54-ФЗ номерлы Федераль законның 8 һәм 12 статьялары;<br>91-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законының 12 статьясы |
| 2.9. Дәүләт хезмәтен күрсәткән өчен алына торган дәүләт пошлинасы яки башка төр түләү алуның тәртибе, күләме һәм нигезләмәләр | Дәүләт хезмәте бушлай күрсәтелә. | |
| 2.10. Дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен зарури һәм мәҗбүри булып торучы хезмәтләр | Зарури һәм мәҗбүри хезмәтләр күрсәтү таләп ителми. | |

| | | |
|---|---|---|
| исемлеге, шул исәптән дәүләт хезмәтен күрсәтүдә катнаша торган оешмалар тарафыннан бирелгән (бирелә торган ) документ (документлар) турындагы мәгълүматлар | | |
| 2.11. Хезмәт күрсәткәнгә, мондый түләү күләмен исәпләү методикасы турындагы мәгълүматны да кертеп, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарур һәм мәҗбүри булган түләү алу тәртибе, күләме һәм нигезләмә | Зарури һәм мәҗбүри хезмәтләр күрсәтү таләп ителми. | |
| 2.12. Дәүләт хезмәтеннән файдалану турында гариза биргәндә яки шундый хезмәт күрсәтүнең нәтиҗәсен алганда чиратта көтеп торуның максималь срогы | Дәүләт хезмәтен алырга тиешле кешенең кабул итүне (хезмәт күрсәтүне) көтүендә максималь вакыт 15 минут.<br>Дәүләт хезмәтен алучыларның аерым категорияләре өчен чират билгеләнмәгән. | РФ Президентының 601 номерлы Указның 1 пунктының “д” пунктчасы |
| 2.13. Дәүләт хезмәтен, шул исәптән электрон формадагысын да, күрсәтүне сорап гариза бирүченең гаризасын теркәү срогы һәм тәртибе | Халык белән чара уздыру турында гариза кергән көнне.<br>Запрос электрон формада ял көннәрендә кергән очракта - запрос кергән көннән соңгы эш көнендә. | |
| 2.14. Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган биналар һәм бүлмәләргә, гариза бирүчеләр көтеп утыра | Дәүләт хезмәте күрсәтү янгынга каршы система һәм янгын сүндерү системасы, документлар рәсмиләштерү өчен кирәкле җиһазлар, мәгълүмати стендлар белән җиһазландырылган | 181-ФЗ номерлы Федераль закон; Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 880 |

| | | |
|---|---|---|
| һәм кабул итеlә торган урыннарга, дәүләт хезмәтен күрсәтү турында гаризалар тутырыла торган урыннарга, һәр төрдәге дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документлар исемлеге һәм тиешле гариза үрнәкләре булган мәгълүмат стендларына, мондый хезмәтләр күрсәтү тәртипләре турындагы күрсәтмә, текст рәвешендәге һәм мультимедия мәгълүматны урнаштыру һәм рәсмиләштерүгә, шул исәптән әлеге объектларның инвалидларны социаль яклау турындагы федераль законар һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә инвалидлар өчен уңайлы булуын тәэмин итүгә таләпләр | биналарда һәм бүлмәләрдә гамәлгә ашырыла.<br>Инвалидларның дәүләт хезмәте күрсәтелә торган урынга киртәләрсез керә алуы (бинага уңайлы керү-чыгу һәм бина чикләрендә уңайлы хәрәкәт) тәэмин ителә.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турындагы күрсәтмә, текст рәвешендәге һәм мультимедия мәгълүмат гариза бирүчегә уңайлы урынга, шул исәптән инвалидларның мөмкинлекләре чикләнгәнлеген исәпкә алып урнаштырыла. | номерлы карары |
| 2.15. Дәүләт хезмәте күрсәтелүнең уңайлылык һәм сыйфат күрсәткечләре, шул исәптән гариза бирүченең дәүләт хезмәте күрсәтелгән чакта урындагы затлар белән үзара хезмәттәшлекләре саны һәм дәвамлылыгы, дәүләт хезмәте күрсәтелү эшенең барышы турында, шул исәптән мәгълүмати-коммуникация технологияләрен файдаланып, мәгълүмат алу мөмкинлеге, дәүләт хезмәтен дәүләт | Дәүләт хезмәте күрсәтелүнең уңайлылык күрсәткечләре булып торалар:<br>бина һәм бүлмәләрнең җәмәгать транспорты килеп җитә торган урында булулары;<br>дәүләт хезмәте күрсәтелә торган бина һәм бүлмәләрнең инвалидлар өчен уңайлы булулары;<br>белгечләрнең, шулай ук гариза бирүчеләрдән документлар кабул ителә торган бина һәм бүлмәләрнең җитәрлек санда булуы;<br>дәүләт хезмәте күрсәтүнең алымнары, тәртибе һәм вакытлары турында мәгълүмат стендларында, Интернет челтәрендә, Министрлыкның рәсми сайтында, Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү бердәм порталында тулы мәгълүмат бирелү;<br>гаризаны электрон вариантта бирү мөмкинлеге;<br>гариза бирүченең дәүләт хезмәте күрсәтелү нәтиҗәләрен | |

| | | |
|---|---|---|
| хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтелә торган күпфункцияле үзәктә, 210-ФЗ номерлы Федераль законның 15[1] статьясында каралган рәвештә дәүләт хзмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтелә торган күпфункцияле органнарында берничә дәүләт хезмәтен күрсәтү турында закрос нәтиҗәсендә гариза бирүченең сайлавы буенча башкарма хакимият органының терәсә-кайсы территориаль органында (экстерриториаль принцип) алу мөмкинлеге яки алып булмау (шул исәптән тулы күләмдә) | электрон рәвештә алу мөмкинлеге;<br>инвалидларга биналарның инвалидлар өчен уңайлылыгына бәйле булмаган, аларга хезмәтләрне башкалар белән тигез дәрәҗәдә алырга комачаулый торган башка киртәләрне үтүдә булышлык итү.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтелүнең сыйфат күрсәткечләре булып торалар:<br>документларны кабул итү һәм карау вакытлары саклану;<br>дәүләт хезмәте күрсәтелүнең нәтиҗәләрен алу вакытлары саклану;<br>әлеге Регламентның Министрлык белгечләре тарафыннан бозылуына нигезле шикаятьләр булмау;<br>гариза бирүченең Министрлык белгечләре белән аралашулары саны:<br><br>дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны биргәндә - бер тапкырдан артык түгел (консультацияне исәпкә алмыйча);<br>дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны почта аша юллаганда – бирәү дә юк (консультацияне исәпкә алмыйча).<br>Дәүләт хезмәтен күрсәткәндә гариза бирүче белән Министрлык белгеченең бер тапкыр үзара аралашуының дәвамлылыгы - 15 минуттан артык түгел.<br>Дәүләт хезмәтләре, дәүләт хезмәтен күрсәтүгә гариза бирүне дә кертеп, күпфункцияле үзәк, күпфункцияле үзәкнең эрактагы эш урыны аша гамәлгә ашырылмый.<br>Дәүләт хезмәтен күрсәтү барышы турындагы мәгълүмат гариза бирүче тарафыннан http://minjust.tatarstan.ru сайтында, Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү бердәм порталында алынырга мөмкин.<br>Дәүләт хезмәтләрен экстерриториаль принцип буенча һәм комплекслы запрос буенча күрсәтү каралмаган. | |
| 2.16. Башка таләпләр, шул исәптән дәүләт хезмәтләрен экстерриториаль принцип буенча | Гариза һәм документлар (документларның күчермәләре) Министрлыкка 63-ФЗ номерлы һәм 210-ФЗ номерлы Федераль законнар таләпләре нигезендә квалификацияле электрон имза | 63-ФЗ номерлы Федераль закон;<br>210-ФЗ номерлы Федераль закон |

| | | |
|---|---|---|
| күрсәтү үзенчәлекләрен исәпкә алган (дәүләт хезмәтләре экстерриториаль принцип буенча күрсәтелгән очракта) һәм дәүләт хезмәтләрен электрон формада күрсәтү үзенчәлекләре | куелган электрон документлар рәвешендә дә юллана ала. | |

## 3.Административ процедураларны (гамәлләрне) башкаруның составы, эзлеклелеге һәм вакытлары, аларны башкару тәртибенә таләпләр, шул исәптән административ процедураларны (гамәлләрне) электрон формада башкару үзенчәлекләре

3.1. Дәүләт хезмәтен күрсәтүдә гамәлләр эзлеклелеге тасвирламасы

3.1.1. Дәүләт хезмәтен күрсәтү үз эченә түбәндәге процедураларны ала:

1) гариза бирүчегә консультация бирү, гариза бирүчегә, шул исәптән дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен зарури булган гаризаны рәсмиләштерү буенча да ярдәм күрсәтү;

2) мөрәҗәгатьне кабул итү һәм теркәү;

3) мөрәҗәгатьне бирүдә җибәрелгән хаталарны төзәтү;

4) министрның мөрәҗәгатьне канәгатьләндерүе яки канәгатьләндерүдән баш тартуы турындагы карар проектын әзерләү;

5) гариза бирүчегә Татарстан Республикасы юстиция министрының мөрәҗәгатьне килештерүе яки килештерүдән баш тартуы туындагы карарын тапшыру;

6) техник хатаны төзәтү.

3.2. Мөрәҗәгать итүчегә консультацияләр бирү, гариза бирүчегә шул исәптән дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү өлешендә дә ярдәм күрсәтү.

Мөрәҗәгать итүче, дәүләт хезмәтен алу тәртибе турында консультацияләр алу өчен, Бүлеккә шәхсән, телефоннан яки почта (шул исәптән электрон почта) аша мөрәҗәгать итүгә хокуклы.

Бүлек белгече мөрәҗәгать итүчегә консультация бирә, шул исәптән мәрәҗәгать формасы һәм дәүләт хезмәте алуга карата башка мәсьәләләр буенча. Кирәк булган очракта Бүлек белгече гариза бирүчегә шул исәптән дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү өлешендә дә ярдәм күрсәтә.

Әлеге пунктта билгеләнелә торган процедура гариза бирүче мөрәҗәгать иткән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедура нәтиҗәсе: консультация, бирелгән документларның составы, формасы һәм эчтәлеге буенча җитешсезлекләрне күрсәтү, гариза бирүчегә ярдәм күрсәтү, шул исәптән дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү өлешендә дә, гражданнарның консультация сорап мөрәҗәгать итүләрен мөрәҗәгатьләрне теркәү жуналына теркәү (гариза бирүчегә ярдәм күрсәтү).

3.3. Гаризаны кабул итү һәм теркәү

3.3.1. Гариза бирүче Министрлыкның Оештыру эшләре һәм документлар әйләнеше бүлегенә (алга таба – Оештыру бүлеге) гаризаны шәхсән китереп бирә.

Гариза шулай ук заказлы хат рәвешендә почта аша да җибәрелергә мөмкин.

Электрон формада җибәрелгән гариза 63-ФЗ номерлы һәм 210-ФЗ номерлы Федераль законнар нигезендә имзалана (раслана) һәм электрон кучергечләрдә һәм (яки) Интернет челтәрен дә кертеп, гомуми кулланылыштагы мәгълүмат - телекоммуникация челтәрләрен файдаланып тапшырыла.

Гариза Татарстан Республикасының дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль

хезмәтләр порталы аша да бирелергә мөмкин.

Заказлы хат рәвешендә почта аша яки электрон формада килгән гаризалар гомуми тәртиптә карала.

3.3.2. Оештыру бүлеге белгече гамәлгә ашыра:

законлы вәкил яки дәүләт хезмәтләрен алучы затның вәкаләтле вәкиле сыйфатындагы гариза бирүченең вәкаләтләрен тикшерүне;

әлеге Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән тиешле барлык документларның да бирелүен һәм аларның билгеләнгән таләпләргә җавап бирүләрен тикшерүне. Тикшерү Бүлек белгече катнашында уздырыла.

Гариза бирүче шәхсән мөрәҗәгать иткәндә Регламентның 2.7. пунктында каралган документларны кабул итүдән баш тарту өчен җирлек булган очракта белгеч гариза бирүчегә документларны кабул итү һәм гаризаны теркәүдән баш тарту өчен җирлек булуы турында аңлата һәм документларны алудан баш тарту өчен табылган җирлек эчтәлеген аңлатып, документларны кире кайтара. Гариза бирүче таләбе буенча баш тарту очрагы язма рәвештә рәсмиләштерелә.

Гариза бирүче гаризаны һәм документларны почта аша (электрон почта аша) җибәргән очракта Оештыру бүлеге белгече аңа документларны, аларны алудан баш тарту өчен табылган җирлек эчтәлеген язмача аңлатып, почта (электрон почта) аша кире кайтара.

Документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигез булмаганда Оештыру бүлеге белгече гамәлгә ашыра:

гаризаны кабул итүне һәм теркәүне;

гаризаның документлар кабул ителү көне, аның керү саны куелган күчермәсен гариза бирүчегә шәхсән тапшыруны яки электрон почта аша (аның теләге буенча) юллауны;

гаризаны Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары документлары әйләнешенең “Электрон Хөкүмәт” бердәй ведомствоара системасы аша (алга таба - электрон документлар әйләнеше) электрон формада Татарстан Республикасы юстиция министрына (алга таба - министр) юллауны.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедура гариза кергән көнне башкарыла.

Процедура нәтиҗәсе: кабул ителгән, теркәлгән һәм министрга юлланган гариза.

3.3.3. Министр гаризаны карый һәм карау өчен министр урынбасарына юллый.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедура гариза теркәлгән көнне башкарыла.

Процедура нәтиҗәсе: карар өчен министр урынбасарына юлланган гариза.

3.3.4. Министр урынбасары гаризаны карый һәм карар өчен Бүлек башлыгына юллый.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура гариза теркәлгән көнне башкарыла.

Процедура нәтиҗәсе: карау өчен Бүлек башлыгына юлланган гариза.

3.3.5. Бүлек башлыгы җаваплы башкаручыны (алга таба – Бүлек белгече) билгели һәм гаризаны эшләү өчен аңа тапшыра.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура гариза теркәлгән көнне башкарыла.

Процедура нәтиҗәсе: эшләү өчен Бүлек белгеченә юлланган гариза.

3.4. Гаризаны килештерү яки гаризаны килештерүдән баш тарту турындагы карарны әзерләү һәм кабул итү

3.4.1. Бүлек белгече:

дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тарту өчен әлеге Регламентның 2.8 пунктында каралган җирлекләрнең булуын (булмавын) билгели;

гавами чара уздыру турындагы гаризаны карый;

гавами чара мәдәни мирас объекты территориясендә уздырылган очракта, гаризаны Мәдәни мирас объектларын саклау буенча Татарстан Республикасы комитеты на юллый;

гаризаны килештерү турында министр карары (алга таба – карар) проектын һәм гаризаны килештерү турында хат проектын (алга таба – килештерү турында хат) әзерли, дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тарту өчен нигез булганда – гаризаны килештерүдән баш тарту турында боерык һәм гаризаны килештерүдән баш тарту турында хат әзерли һәм аны килештерү өчен Бүлек башлыгына юллый.

Кирәк булган очракта, шулай ук шулай ук Мәдәни мирас объектларын саклау буенча Татарстан Республикасы комитетыннан гавами чараны мәдәни мирас объектлары (тарихи һәм мәдәни ядкәрләр) территориясендә, ачыкланган мәдәни мирас объектлары территорияләрендә уздыру мөмкин булмавы турында бәяләмә алган очракта үз эченә халык белән чараны уздыру урыны һәм (яки) вакыты үзгәрү турында нигезле тәкъдимне алган хат проектын, шулай ук халык белән чараны оештыручыга гаризада күрсәтелгән максатларның, формаларның һәм башка шартларның халык белән чараны уздыруның 54-ФЗ номерлы Федераль закон таләпләренә туры килми торган урыннарын бетерү турында тәкъдим (алга таба –хат-тәкъдим) әзерли һәм аны килештерү өчен Бүлек башлыгына юллый.

Халык белән чара уздыру турында белдерү текстында булган мәгълүмат һәм башка мәгълүматлар халык белән планлаштырылган чараның максатлары һәм аны уздыру формалары Россия Федерациясе Конституциясе нигезләмәләренә туры килми дип санарга җирлек калдырган һәм (яки) Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе законнарында яки җинаять җаваплылыгы турындагы законнарда каралган тыюларны бозган очракта Бүлек белгече үз эченә халык белән чараны оештыручының яки чарада катнашучы башка кешеләрнең мондый җитешсезлекләр табылган очракта һәм (яки) мондый чараны уздыру барышында закон белән каралган тыюлар бозылган очракта билгеләнгән тәртиптә җаваплылыкка тартылу мөмкинлеге турында мотивлаштырылган кисәтүне (алга таба – кисәтү) алган хат проектын әзерли һәм аны килештерү өчен Бүлек башлыгына юллый.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура гариза башкару өчен Бүлек белгеченә юлланган мизгелдән ике эш көне дәвамында гамәлгә ашырыла. Мәдәни мирас объектларын саклау буенча Татарстан Республикасы комитеты белән килештерү кирәк булган очракта - гариза башкару өчен Бүлек белгеченә юлланган мизгелдән өч эш көне дәвамында гамәлгә ашырыла.

Процедура нәтиҗәсе: килештерү өчен Бүлек башлыгына юлланган карар проекты, килештерү турында хат, хат-тәкъдим, кисәтү проектлары.

3.4.2. Бүлек башлыгы гаризаны карау нәтиҗәләрен тикшерә, карар проекты, килештерү турындагы хат, хат-тәкъдим, кисәтү проектларын килештерә һәм аларны килештерү өчен министр урынбасарына юллый.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура билгеләнгән проектлар килештерү өчен Бүлек башлыгына кергән көнне башкарыла.

Процедура нәтиҗәсе: килештерү өчен министр урынбасарына юлланган карар проекты, килештерү турындагы хат, хат-тәкъдим, кисәтү проектлары.

3.4.3. Министр урынбасары карар проектын, килештерү турындагы хатны, хат-тәкъдимне, кисәтү проектларын килештерә һәм аларны министрга юллый.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура әлеге проектлар килештерүгә кертелгән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедура нәтиҗәсе: килештерелгән һәм имзалау өчен министрга юлланган карар проекты, килештерү турындагы хат, хат-тәкъдим, кисәтү проектлары.

3.4.4. Министр карар проектын, килештерү турындагы хатны, хат-тәкъдимне, кисәтү проектларын имзалый. Имзаланган карар проекты, килештерү турындагы хат, хат-тәкъдим, кисәтү Бүлеккә юллана.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура әлеге проектлар имзалауга кергән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедура нәтиҗәсе: министр тарафыннан имзаланган карар, килештерү турындагы хат, хат-тәкъдим, кисәтү.

3.4.5. Бүлек белгече:

министр карарына тәртип саны билгели;

гариза язучыга дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәсе турында белдерүдә күрсәтелгән элемтә чарасын кулланып хәбәр итә, халык белән чара уздыру турында гаризаны килештерү яки килештерүдән баш тарту турындагы карарны бирү көнен һәм вакытын белдерә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура карар, хат, кисәтү министр тарафыннан имзаланган көнне гамәлгә ашырыла.

Процедура нәтиҗәсе: теркәү өчен Оштыру бүлегенә тапшырылган карар, килештерү турындагы хат, хат-тәкъдим, кисәтү.

3.5. Гариза бирүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен юллау

3.5.1. Оештыру бүлеге белгече:

килештерү турындагы хатны, хат-тәкъдимне, кисәтүне карар күчермәсе белән бергә терки;

документларның Министрлыкка тапшырылу алымыннан чыгып гариза язучыга гаризаны килештерү турында карар күчермәсе белән булган хатны бирә (юллый), әлеге Регламентның 3.4.1 пунктының алтынчы һәм җиденче абзацларында күрсәтелгән очракларда югарыда әйтелгән документларга хат-тәкъдим һәм (яки) кисәтү дә өстәп бирелә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар карарга, хатка, кисәтүгә министр тарафыннан имза салынга көнне гамәлгә ашырыла.

Процедура нәтиҗәсе: гариза бирүчегә карар, хат-тәкъдим, кисәтү күчермәләре өстәлеп бирелгән (юлланган) килештерү турындаы хат.

3.6. Татарстан Республикасы Хөкүмәте порталының Интернет-кабул итү

бүлмәсе аша кергән гаризаны карау.

Интернет-кабул итү бүлмәсе аша кергән гариза әлеге Регламентның 3.3 – 3.5 пунктларында каралган тәртиптә теркәлә һәм карала.

3.7. Гаризаны биргәндә җибәрелгән хаталарны төзәтү.

3.7.1. Бүлек белгече:

54-ФЗ номерлы Федераль закон таләпләре бозылу һәм гариза бирүнең 91-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы белән билгеләнгән тәртибе бозылу ачыкланганда халык белән чараны оештыручыга табылган җитешсезлекләрне төзәтү турында хат проекты (алга таба – хат проекты) әзерли.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура гариза кергән мизгелдән бер эш сәгате дәвамында гамәлгә ашырыла.

Процедура нәтиҗәсе: халык белән чара оештыручыга табылган җитешсезлекләрне бетерү турында хат проекты.

3.7.2. Бүлек башлыгы 54-ФЗ номерлы Федераль закон таләпләре бозылу һәм гариза бирүнең 91-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы белән билгеләнгән тәртибе бозылу турындагы нәтиҗәләрнең нигезлелеген тикшерә, хат проектын килештерә һәм аны килештерү өчен министр урынбасарына юллый.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура хат проекты кергән мизгелдән бер эш сәгате дәвамында башкарыла.

Процедура нәтиҗәсе: килештерү өчен министр урынбасарына юлланган хат проекты.

3.7.3. Министр урынбасары хат проектын килештерә һәм аны министрга юллый.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура хат проекты кергән мизгелдән бер эш сәгате дәвамында башкарыла.

Процедура нәтиҗәсе: килештерү өчен министрга юлланган хат проекты.

3.7.4. Министр хат проектын имзалый. Имзаланган хат проекты Оештыру бүлегенә юллана.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура хат проекты кергән мизгелдән бер эш сәгате дәвамында башкарыла.

Процедура нәтиҗәсе: министр тарафыннан имзаланган хат проекты (алга таба - хат).

3.7.5. Оештыру бүлеге белгече:

х атны терки;

документларның Министрлыкка тапшырылу алымыннан чыгып гариза язучыга 54-ФЗ номерлы Федераль закон таләпләре һәм гариза бирүнең 91-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законында билгеләнгән тәртибенең бозылуы турында хат бирә (юллый).

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура хат проекты Оештыру бүлеге белгеченә кергән мизгелдән бер эш сәгате дәвамында башкарыла.

Процедура нәтиҗәсе: халык белән чараны оештыручыга 54-ФЗ номерлы Федераль закон таләпләре һәм гариза бирүнең 91-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законында билгеләнгән тәртибенең бозылуы турында бирелгән (юлланган) хат.

3.8. 54-ФЗ номерлы Федераль закон таләпләре һәм гариза бирүнең 91-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законында билгеләнгән тәртибенең бозылуы төзәтелгәннән соң кергән гаризаны карау.

Халык белән чараны оештыручы тарафыннан 54-ФЗ номерлы Федераль закон таләпләре бозылу һәм гариза бирүнең 91-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы белән билгеләнгән тәртибе бозылу төзәтелгәннән соң халык белән чара уздыруга кадәр өч календарь көннән артыграк вакыт калса, гариза әлеге Регламентның 3.3-3.5 пунктларында каралган тәртиптә ике календарь көн дәвамында карала.

Әгәр дә чараны уздыруга кадәр өч календарь көннән кимрәк вакыт калган булса, халык белән чараны оештыручы башка дата тәкъдим итәргә тиеш, һәм гариза әлеге Регламентның 3.3-3.5 пунктларында каралган тәртиптә килештерелә. Халык белән чараны уздыруның башка датасы турындагы тәкъдим аны оештыручыларга әлеге Регламентның 3.3.1 пунктында күрсәтелгән алымнар белән юллана.

Халык белән чараны оештыручы тарафыннан 54-ФЗ номерлы Федераль закон таләпләре һәм гариза бирүнең 91-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законында билгеләнгән тәртибенең бозылуы бетерелгәнчегә кадәр гариза алга таба карала алмый, ә чара килештерелмәгән булып санала.

3.9. Техник хатаны төзәтү

Карарны кабат рәсмиләштерү гариза бирүчегә алдарак бирелгән карарда җибәрелгән техник хатаны (хәреф хатасы, грамматик яки арифметик хата) төзәтү белән бәйле рәвештә башкарыла.

Карарны кабат рәсмиләштерү ирекле формада язылган һәм әлеге Регламентның 3.3.1 пунктында күрсәтелгән алымнарның берсе аша бирелә торган теркәлгән гариза нигезендә башкарыла (тәкъдим ителә торган форма әлеге Регламентка 2 нче кушымтада китерелгән).

3.9.1 Оештыру бүлеге белгече гамәлгә ашыра:

гаризаны кабул итүне һәм теркәүне;

гаризаны электрон документлар әйләнешенең бердәй ведомствоара системасы аша электрон формада министрга юллауны.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедура гариза кергән көнне башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: кабул ителгән, теркәлгән һәм министрга юлланган гариза.

3.9.2. Министр гаризаны карый һәм карау өчен министр урынбасарына юллый.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедура гариза теркәлгән көнне башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: карау өчен министр урынбасарына юлланган гариза.

3.9.3. Министр урынбасары гаризаны карый һәм карау өчен Бүлек башлыгына юллый.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедура гариза теркәлгән көнне башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: карау өчен Бүлек башлыгына юлланган гариза.

3.9.4. Бүлек башлыгы Бүлек белгечен билгеләп куя һәм башкару өчен аңа гаризаны тапшыра.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедура гариза Бүлеккә юлланган мизгелдән бер эш көне дәвамында башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: эшләү өчен Бүлек белгеченә тапшырылган гариза.

3.9.5. Бүлек белгече:

техник хатаны төзәтеп карар проектын әзерли;

карар проектын килештерү өчен Бүлек башлыгына юллый.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедуралар гариза эшләү өчен Бүлек белгеченә юлланган көннән бер эш көне эчендә башкарыла.

Процедура нәтиҗәсе: килештерү өчен Бүлек башлыгына юлланган карар проекты.

3.9.6. Бүлек башлыгы әзерләнгән карар проектының дөреслеген тикшерә, аны килештерә һәм килештерү өчен министр урынбасарына юллый.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедура карар проекты килештерү өчен Бүлек башлыгына кергән көнне башкарыла.

Процедура нәтиҗәсе: килештерү өчен министр урынбасарына юлланган карар проекты.

3.9.7. Министр урынбасары карар проектын килештерә һәм аны килештерү өчен министрга юллый.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедура карар проекты Бүлек башлыгыннан кергән көнне башкарыла.

Процедура нәтиҗәсе: килештерелгән карар проекты.

3.9.8. Министр кабат рәсмиләштерелгән карарны имзалый.

Имзаланган карар Бүлеккә юллана.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедура килештерелгән карар проекты имзалауга кергән көнне башкарыла.

Процедура нәтиҗәсе: имзаланган кабат рәсмиләштерелгән карар.

3.9.9. Бүлек белгече:

кабат рәсмиләштерелгән карарга беренчел карар теркәлгән тәртип саны билгели;

гариза бирүчегә гариза бирүченең теләге буенча документның әзерлеге турында техник хатаны төзәтү турындагы гаризада яки дәүләт хезмәтен күрсәтүне сораган мөрәҗәгатьтә күрсәтелгән элемтә алымы белән хәбәр итә;

гариза бирүче кабат рәсмиләштерелгән карарны шәхсән килеп алырга теләк белдергән очракта, килеп алу көнен һәм сәгатен хәбәр итә;

карарның күчермәсен Оештыру бүлегенә тапшыра.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедуралар кабат рәсмиләштерелгән карар имзаланган көнне башкарыла.

Процедура нәтиҗәсе: теркәлгән карар, карар күчермәсен алу турында гариза бирүче белән килештерелгән алым.

3.9.10. Оештыру бүлеге белгече гариза бирүченең теләге буенча карар күчермәсен гариза бирүчегә шәхсән тапшыра яки гаризада күрсәтелгән адрес буенча юллый.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедура министр карарны имзалаган көнне башкарыла.

Процедура нәтиҗәсе: техник хата төзәтелгән карарның бирелгән (юлланган) күчермәсе.

4. Административ регламентны үтәүне контрольдә тоту тәртибе һәм формалары

4.1. Министрлыкның урындагы затлары тарафыннан Регламент нигезләмәләренең һәм дәүләт хезмәтен күрсәтүгә таләпләр билгели торган башка норматив хокукый актларның сакланышын һәм үтәлешен, шулай ук алар тарафыннан карарлар кабул ителүне тикшерүдә тоту әлеге административ процедураның үтәлеше өчен җаваплы зат һәм министрның дәүләт хезмәтен күрсәтү буенча эшләрне оештыру өчен җаваплы урынбасары тарафыннан гамәлгә ашырыла.

Дәүләт хезмәтен күрсәтүнең тулылыгын һәм сыйфатлылыгын тикшерүдә тоту үз эченә тикшерүләр үткәрүне, карарларны карау һәм кабул итүне, дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен җаваплы урындагы затларның карарларына, гамәлләренә (гамәлләр кылмауларына) шикаять белдергән мөрәҗәгатьләргә җаваплар әзерләүне ала.

Административ процедураларны үтәүне тикшерүдә тоту формалары булып тикшерү уздыру тора:

эш башкаруны алып баруга;

документларны карау нәтиҗәләренең закон таләпләренә (әлеге Регламентка) туры килүенә;

документларны кабул итү вакытларын һәм тәртибен саклауга;

дәүләт хезмәтен күрсәткәндә нәтиҗәләрне бирү вакытларын һәм тәртибен саклауга.

Тикшерүләрне башкаруның кабатланучанлыгы планлы (эш планнары нигезендә башкарыла) һәм плансыз (гариза бирүченең анык мөрәҗәгате буенча) рәвештә башкарыла.

4.2. Үткәрелгән тикшерүләр нәтиҗәләре буенча гариза бирүчеләрнең хокукларын бозу очрагы ачыкланса, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен җаваплы булган һәм гаепле дип табылган затлар, Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән тәртиптә җаваплылыкка тартылалар.

4.3.Дәүләт хезмәтләре күрсәтелүне гражданнар, аларның берләшмәләре һәм оешмалары ягыннан тикшерүдә тоту Министрлыкның дәүләт хезмәтләре күрсәтүдәге эшчәнлегенең ачыклыгы, дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында тулы, актуаль һәм дөрес мәгълүматлар алу һәм дәүләт хезмәте күрсәтү процессында мөрәҗәгатьләрне (шикаятьләрне) судка кадәр карау мөмкинлеге юлы белән гамәлгә ашырыла.

5. Дәүләт хезмәтен күрсәтүче органның, дәүләт хезмәтләрен һәм муниципаль хезмәтләрне күрсәтүче күпфункцияле үзәкнең, шулай ук вазыйфаи затларның, дәүләт хезмәткәрләренең карарларына, кылган гамәлләренә (гамәл кылмауларына) карата судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү тәртибе

5.1. Дәүләт хезмәтен күрсәтүне сорап мөрәҗәгать итүчеләр Министрлыкның, Министрлыкның вазыйфаи затының яки дәүләт хезмәткәренең карарларына, кылган гамәлләренә (гамәл кылмауларына) карата судка кадәр Министрлыкка шикаять белдерүгә хокуклылар. Дәүләт хезмәтен күрсәтүгә бәйле рәвештә министр кабул

иткән карарларга карата белдерелгән шикаятьләр Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына бирелә.

Мөрәҗәгать итүче шикаять белән шул исәптән түбәндәге очракларда да мөрәҗәгать итә ала:

1) дәүләт хезмәте күрсәтү турында мөрәҗәгать итүченең запросын теркәү срогы бозылганда;

2) дәүләт хезмәте күрсәтү срогы бозылганда;

3) мөрәҗәгать итүчедән дәүләт хезмәте күрсәтү өчен Россия Федерациясенең норматив-хокукый актларында, Татарстан Республикасының норматив-хокукый актларында күздә тотылмаган документлар, мәгълүматлар яки гамәлләр кылу таләп ителгәндә;

4) дәүләт хезмәте күрсәтү турында мөрәҗәгать итүчедән Россия Федерациясе норматив-хокукый актларында, Татарстан Республикасының норматив-хокукый актларында күздә тотылган документларны кабул итеп алудан баш тартканда;

5) дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тартканда, әгәр баш тартуга нигезләр федераль законнар һәм Россия Федерациясенең алар нигезендә кабул ителгән башка норматив-хокукый актлары, Татарстан Республикасының норматив-хокукый актлары нигезендә күздә тотылмаса;

6) дәүләт хезмәте күрсәткәндә мөрәҗәгать итүчедән Россия Федерациясенең норматив-хокукый актларында, Татарстан Республикасының норматив-хокукый актларында күздә тотылмаган түләү таләп иткәндә;

7) Министрлык, Министрлыкның вазыйфаи заты дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документлардагы ялгыш язуларны һәм хаталарны төзәтүдән баш тартканда яки мондый төзәтүләрнең билгеләнгән срогын бозганда;

8) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләре буенча документларны бирү срогы яисә тәртибе бозылганда;

9) дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып торганда, әгәр федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең бүтән норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы законнарында һәм норматив хокукый актларында туктатып тору өчен нигезләр каралмаган булса;

10)дәүләт хезмәтен күрсәткәндә гариза бирүчедән документларны кабул итүдән беренче тапкыр баш тартканда аларның булмавы һәм (яки) дөрес түгеллекләре күрсәтелмәгән, дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле булган, яки дәүләт хезмәтен күрсәткән чакта кирәкле булган документлар яки мәгълүмат таләп итү, «Дәүләт хезмәтләрен һәм муниципаль хезмәтләрне күрсәтүне оештыру турында» 210-ФЗ номерлы Федераль законның 7 статьясындагы 1 өлешнең 4 пунктында каралган очраклардан тыш.

5.2. Шикаять почта аша, күпфункцияле үзәк аша, “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәреннән, Министрлыкның рәсми сайтыннан, Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең бердәй порталы яки Татарстан Республикасының дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр порталыннан файдаланып җибәрелә ала, шулай ук гариза бирүчедән шәхсән кабул ителергә мөмкин.

5.3. Шикаять үз эченә түбәндәге мәгълүматларны алырга тиеш:

карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаять белдерелә торган Министрлыкның, Министрлыкның вазыйфаи затының яки дәүләт граждан хезмәткәренең исемен;

гариза бирүче - физик затның фамилиясе, исеме, әтисенең исеме (булса), яшәү урыны турында мәгълүматлар яки юридик затның исеме, урнашкан урыны турында мәгълүматлар, шулай ук элемтә телефоны номеры (номерлары), гариза язучыга җавап җибәрелергә тиешле электрон почта (булса) адресы (адреслары) һәм почта адресы;

Министрлыкның, аның вазыйфаи затының яисә дәүләт хезмәткәренең шикаять белдерелә торган карарлары һәм кылган гамәлләре (гамәл кылмаулары) турында мәгълүматлар;

мөрәҗәгать итүченең Министрлыкның, аның вазыйфаи затының яисә дәүләт хезмәткәренең карары һәм кылган гамәлләре (гамәл кылмавы) белән килешмәвенә дәлилләре.

5.4. Гариза бирүче тарафыннан гариза бирүченең дәлилләрен раслаучы документлар (яки аларның күчермәләре) тапшырыла ала (алар булган очракта).

5.5. Шикаятьне карау срогы - шикаять теркәлгән көннән 15 көне дәвамында. Ә Министрлыкның, Министрлыкның урындагы затының гариза бирүчедән документларны кабул итеп алудан баш тартуына, документта җибәрелгән хатаны төзәтүдән баш тартуына яки мондый төзәтмәләр кертелү вакыты бозылуга шикаять белдерелгән очракта - шикаять теркәлгән көннән биш эш көне дәвамында каралырга тиеш.

5.6. Шикаять шәхсән яки гариза бирүченең вәкаләтле вәкиле тарафыннан имзалана.

5.7. Шикаятьне карау нәтиҗәләре буенча түбәндәге карарларның берсе кабул ителә:

1)шикаятьне канәгатьләндерә, шул исәптән кабул ителгән карарны юкка чыгару, дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәләре турында бирелгән документларда җибәрелгән хаталарны төзәтү, гариза язучыга аларны алу Россия Федерациясенең норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасының норматив хокукый актларында каралмаган акчаларны кире кайтару формаларында;

2)шикаятьне канәгатьләндерүдән баш тарта.

Гариза язучыга әлеге пунктта күрсәтелгән карар кабул ителгән көннән соң килүче көннән дә соңга калмыйча язма формада һәм гариза язучының теләге буенча, электрон формада да, шикаять каралу нәтиҗәләре турында мотивлаштырылган җавап җибәрелә.

5.8. Шикаять канәгатьләндерелүгә лаек дип танылган очракта гариза бирүчегә җавапта Министрлык тарафыннан дәүләт хезмәтен күрсәткән чакта табылган җитешсезлекләрне кичекмәстән төзәтү максатыннан гамәлгә ашырылачак гамәлләр турында мәгълүмат бирелә, шулай ук килеп туган уңайсызлыклар өчен гафу сорала һәм гариза бирүче тарафыннан дәүләт хезмәтен алу максатыннан башкарылырга тиешле гамәлләр турында мәгълүмат бирелә.

5.9. Шикаять канәгатьләндерелүгә лаек түгел дип танылган очракта гариза бирүчегә җавапта мондый карар кабул ителү сәбәпләре турында нигезле аңлатмалар,

шулай ук кабул ителгән карарга шикаять бирдерү тәртибе турында мәгълүмат бирелә.

5.10. Шикаятьне карау барышында яки аның нәтиҗәләре буенча административ хокук бозулар яки җинаять составы ачыкланган очракта шикаятьләрне карау буенча урындагы зат булган материалларны кичекмәстән прокуратура органнарына юллый.

Татарстан Республикасында
берничә муниципаль район,
шәһәр округы территориясендә
халык белән чараларны уздыруны
килештерү буенча дәүләт
хезмәте күрсәтүнең
административ регламентына
1 нче кушымта
(тәкъдим ителә торган форма)

Татарстан Республикасы
юстиция министры
Р.И.Заһидуллинга

____________________
(физик затлар өчен: ФИӘ.и. (соңгысы – булганда),
адрес (почта һәм (яки) электрон),
телефон, кәрәзле телефонны да кертеп

______________________________
юридик затлар өчен: оешманың исеме,
адрес (почта һәм (яки) электрон),
телефон, кәрәзле телефонны да кертеп

Халык белән чара уздыру турында белдерү

___________________________________________________________________
(оештыручының исеме) халык белән чара уздырылуы турында белдерә(м)

Халык белән чараның максаты __________________________
Халык белән чараның формасы __________________________
Халык белән чараны уздыру урыны (урыннары), катнашучыларның хәрәкәт маршрутлары, транспорт чараларын файдалану турындагы мәгълүмат
Халык белән чараны уздыру көне, аның башлану һәм тәмамлану вакыты ___________________________________________________________
Халык белән чараны оештыручының җәмәгать тәртибен_____________________________________________
медицина ярдәмен_______________________________________________
тәэмин итү формалары һәм алымнары.
Халык белән чараны уздырганда тавыш көчәйткеч техник чараларны куллану нияте ______________________________________
Халык белән чараны оештыручының фамилиясе, исеме, әтисенең исеме (соңгысы – булганда) яки атамасы, аның яшәү яки тору урыны турында мәгълүматлар, телефон номеры _____________________________________________________________
Халык белән чараны оештыручы тарафыннан халык белән чараны оештыру һәм уздыру буенча гамәлләр башкаруга вәкаләт бирелгән затларның фамилиясе, исеме, әтисенең исеме (соңгысы – булганда)
__________________________________________________
Документның әзерлеге турында белдерүегезне үтенәм ____________________________________________________________________
(белдерү алымы)

Шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә (җыюга, системалаштыруга, саклауга, аныклауга (яңартуга, үзгәрешләр кертүгә), файдалануга, таратуга (шул исәптән тапшыруга), шәхесне күрсәтмәүгә, блокировать итүгә, шәхси мәгълүматларны юкка чыгаруга, шулай ук дәүләт хезмәтен күрсәтү кысаларында шәхси мәгълүматларны эшкәртү өчен кирәкле башка гамәлләргә, шул исәптән автомат режимда, алар нигезендә дәүләт хезмәтен күрсәтүче органнар тарафыннан дәүләт хезмәтен күрсәтү максатыннан карарлар кабул ителүгә үз ризалыгымны, шулай ук мин тәкъдим итә торган затның ризалыгын раслыйм.

___________________
(гаризаны бирү көне

______________________________________________
(халык алдындагы чараны оештыручы һәм халык
алдындагы чараны оештыручы тарафыннан
аны оештыру һәм уздыру буенча гамәлләр
башкаруга вәкаләт бирелгән затларның имзалары)

Татарстан Республикасында
берничә муниципаль район,
шәһәр округы территориясендә
халык белән чараларны уздыруны
килештерү буенча дәүләт
хезмәте күрсәтүнең
административ регламентына
2 нче кушымта
(тәкъдим ителә торган форма)

Татарстан Республикасы
юстиция министры
Р.И.Заһидуллинга

____________________
(физик затлар өчен: ФИӘ.и. (соңгысы – булганда),
адрес (почта һәм (яки) электрон),
телефон, кәрәзле телефонны да кертеп

________________________________
юридик затлар өчен: оешманың исеме,
адрес (почта һәм (яки) электрон),
телефон, кәрәзле телефонны да кертеп

Техник хатаны төзәтү турында гариза

Халык алдындагы чараны үткәрүне килештерү турындагы карарда хата җибәрелүе турында белдерәм.

____________________________________________________________
(бирелгән документ) диелгән_________________________________________________________________.
Дөрес мәгълүматлар: ______________________________________________________________________
Җибәрелгән техник хатаны төзәтүегезне һәм дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булып торучы документка тиешле үзгәрешләр кертүегезне сорыйм.
Түбәндәге документларны терким:
1.
2.
Документның әзерлеге турында белдерүегезне үтенәм ______________________________________________________________________
(белдерү алымы)
________________________ (____________________________________)
(дата) (имза) (имзаны тутырып язу)

Татарстан Республикасында
берничә муниципаль район,
шәһәр округы территориясендә
халык белән чараларны уздыруны
килештерү буенча дәүләт
хезмәте күрсәтүнең
административ регламентына
кушымта (белешмәлек)

Берничә муниципаль район, шәһәр округы территориясендә халык белән чараларны уздыруны килештерү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүгә һәм дәүләт хезмәте күрсәтелүне тикшерүдә тотуга җаваплы урындагы затларның реквизитлары

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы

| Вазыйфа, ФИӘ.и. | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| Министр | (843) 292-00-70 | minjust@tatar.ru |
| Министр урынбасары | (843) 292-00-53 | M.Ibyatov@tatar.ru |
| Оештыру эшләре һәм документлар әйләнеше бүлеге башлыгы | (843) 223-07-60 | Farida.Nurieva@tatar.ru |
| Җирле үзидарә органнарына хокукый консультация-методик ярдәм күрсәтү бүлеге башлыгы | (843) 223-06-47 | Mayya.Pashkova@tatar.ru |

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты

| Адрес | Вазыйфа | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|---|
| 420014, Казан шәһ., Ирек мәйданы, 1 | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының хокукый идарә башлыгы | (843) 264-76-25 | Andrey.Grevcov@tatar.ru |